**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 30 декабрь | № 1021

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән расланган «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 13 декабрь, 980 нче, 2014 ел, 25 декабрь, 1027 нче, 2015 ел, 24 декабрь, 967 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 76 212,89 млн. сум тәшкил итә, шул исәптән:<br><br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы - 14 595,87 млн. сум;<br><br>федераль бюджет акчасы - 19 340,87 млн. сум; |

бюджеттан тыш чыганаклар - 42 276,15 млн. сум:

(млн. сум)

| Ел | Барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Россия Федерациясе бюджеты акчасы | Бюджеттан тыш чыганаклар акчасы |
|---|---|---|---|---|
| 2013 | 4 690,94 | 989,58 | 1 441,55 | 2 259,80 |
| 2014 | 5 305,94 | 926,60 | 1 072,88 | 3 306,45 |
| 2015 | 4 177,15 | 808,79 | 876,69 | 2 491,67 |
| 2016 | 4 094,50 | 810,54 | 933,33 | 2 350,62 |
| 2017 | 6 677,49 | 1 196,92 | 1 626,17 | 3 854,41 |
| 2018 | 3 852,19 | 748,49 | 1 326,59 | 1 777,09 |
| 2019 - 2023 | 47 414,67 | 9 114,93 | 12 063,65 | 26 236,08 |
| Барлыгы: | 76 212,89 | 14 595,87 | 19 340,87 | 42 276,15 |

Программа чараларын үтәү өчен кирәкле финанс ресурслары күләмнәре Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм федераль бюджеттан акча бүлеп бирү мөмкинчелегенә карап, шулай ук базар конъюнктурасы үзгәрүгә бәйле рәвештә ел саен коррекцияләнә торган Программаны тормышка ашыру чараларының нигезле еллык планнары нигезендә ачыкланачак. Аларны финанслау буенча карарлар әлеге максатларга бюджет акчасы булганда һәм аларны федераль бюджеттан финанслашу шартларында, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең аерым актлары белән кабул ителергә тиеш»;

«Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру буенча көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«кимендә 1500 автотранспорт чарасын КТГ куллануга яңадан җиһазландыру»;

Программаның 2 бүлегендә:

бүлеккә түбәндәге эчтәлекле егерме алтынчы абзац өстәргә:

«Икенче этапта ТКГда эшләүче автотранспорт сатып алу, шулай ук АКТГСның гамәлдәге куәтләрен һәм яңа станцияләр төзүне исәпкә алып, автотранспорт чарасын КТГ куллануга яңадан җиһазландыру белән синхронлаштырып, ГМЯ базарын үстерүгә һәм аңарга сервис хезмәте күрсәтүгә аеруча игътибар биреләчәк.»;

бүлеккә түбәндәге эчтәлекле утыз беренче абзац өстәргә:

«кимендә 1500 автотранспорт чарасын КТГ куллануга яңадан җиһазландыру»;

13 нче таблицадан соң бүлеккә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«3. Автотранспорт чараларын КТГ куллануга яңадан җиһазландыру.

Әлеге юнәлештә төп чаралар булып түбәндәгеләр тора:

мотор ягулыгы сыйфатында КТГ куллануга яңадан җиһазландыру планлаштырылган автотранспорт чараларының төрен һәм санын билгеләү;

автотранспорт чараларын яңадан җиһазландыру һәм аларга техник хезмәт күрсәтү пунктларының туктаусыз эшен тәэмин итү;

таләп ителә торган күләмнәрдә газ-баллон җиһазлары комплектлары һәм җайланмалар китерүне тәэмин итү.»;

Программаның 3 бүлегендә:

бүлекнең беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанслауның гомуми күләме 76 212,89 млн. сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы - 14 595,87 млн. сум, федераль бюджет акчасы - 19 340,87 млн. сум, бюджеттан тыш чыганаклар - 42 276,15 млн. сум.

Программа чараларын финанслау күләмнәре ел саен тәгаенләнә (14 – 18 нче таблицалар).»;

бүлеккә түбәндәге эчтәлекле яңа 16 нчы таблица өстәргә:

«ГМЯдагы автотранспорт чараларын яңадан җиһазландыру буенча финанслау сценарийләре (II Этап – 2014 – 2018 еллар)

| Транспорт чарасы исеме | Гомуми саны, берәмлек | 2016 елга күздә тотылган финанслау күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | БАРЛЫГЫ | алардан | | |
| | | | федераль бюджет | Татарстан Республикасы бюджеты | предприятиеләр акчасы |
| Физик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрнең автотранспорт чаралары | 1 500 | 375 000 | 0 | 75 000 | 300 000»; |

16, 17, 18 һәм 19 нчы таблицаларны тиешенчә 17, 18, 19 һәм 20 нче таблицалар дип санарга;

Программаның 6 бүлегендә:

19 нчы таблицага түбәндәге эчтәлекле икенче юл өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «Автотранспорт чараларын ГМЯ куллануга яңадан җиһазландыру» | 0 | 1 500 | 0 | 1 500»; |

икенче – алтынчы юлларны тиешенчә өченче – җиденче юллар дип санарга;

Программага кушымтада:

4 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле икенче яңа юл өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2. Республикада эксплуатацияләнүче автотранспорт | ТР Икътисад министрлыгы, Татарстан | ГМЯда эшли торган автотранспорт | 1 500 | 375 000 | 0 | 75 000 | 300 000 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| чараларын ГМЯ куллануга яңадан җиһазландыру | Республикасы министрлыклары һәм ведомство-лары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары | чараларын яңадан җиһаз-ландыру, берәмлек | | | | | |

4 нче таблицаның 2,3 һәм 4 юлларын тиешенчә 3,4 һәм 5 юллар дип санарга;

«БАРЛЫГЫ» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «БАРЛЫГЫ» | | | | 4 094 500 | 933 330 | 810 545 | 2 350 625 |

файдаланылган кыскартулар исемлегенә түбәндәге юлны өстәргә:

«ТР Икътисад министрлыгы» - Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1021.docx